ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОЧЕЛНИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НУРЛАТСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ЧАЛЛЫ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ Иске Чаллы авылы КАРАР

№ 64 «23» декабрь 2019

2020 елга Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә хөкем ителгәннәргә административ җәза үтәү өчен мәҗбүри эшләр төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында

«Татарстан Республикасы җирле үзидарә органнары тарафыннан мәҗбүри эш төрләрен һәм оешмалар исемлеген билгеләү турында» 16.11.2012 ел, ПР-43-6 номерлы Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Советы Президиумының карарын үтәү йөзеннән (Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексына 2012 елның 8 июнендә кертелгән үзгәрешләргә бәйле рәвештә), мәҗбүри эшләр рәвешендә административ җәза билгеләнгән затларны төзәтү, аларда нормаларга, җәмгыять кагыйдәләренә, иҗтимагый-файдалы хезмәткә ихтирамлы мөнәсәбәт булдыру максатларында), административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 32.13 статьясы нигезендә һәм законлы көченә кергән суд карары буенча административ җәза үтәү рәвешендәге мәҗбүри эшләрнең мәҗбүри хезмәт булып саналуын исәпкә алып, Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Иске Чаллы авыл җирлеге территориясе чикләрендә: Иске Чаллы авылы, Түбән Чаллы авылы, Урта Чаллы авылы торак пунктларында (җинаять-башкарма инспекциясе белән килештереп) мәҗбүри эшләр рәвешендәге җәза үтәү урыннарын билгеләргә.
2. Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри эшләр рәвешендә җәза үтәтү объекты итеп Иске Чаллы авыл җирлеге администрациясен (җинаять-башкарма инспекциясе белән килештереп) билгеләргә.
3. Мәҗбүри эшләрнең төрләрен - торак пунктларны төзекләндерү, чистарту һәм яшелләндерү, зиратларны төзекләндерү, зиратларны чистарту, юлларны һәм буаларны чистарту, елгалар һәм чишмәләр территорияләрен санитар чистарту, юлларны һәм башка тышкы төзекләндерү объектларын ремонтлау, төяү-бушату эшләре, алдан һәм һөнәри әзерлек таләп ителми торган хезмәт эшчәнлегенең һәркем файдалана алырлык башка төрләрен (җинаять - башкарма инспекция белән килештереп) билгеләргә.
4. Әлеге карарны, төзәтү эшләренә хөкем ителгән һәм Иске Чаллы авыл җирлеге территориясендә яшәүче затларга карата суд карарлары үтәлешен тәэмин итү өчен, Россия җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Нурлат муниципальара филиалы ФКУнә җибәрергә.
5. Әлеге карарны «Интернет» челтәрендәге мәгълүмат стендларында һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Захаров

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 23 декабрендәге 64 номерлы карарына Килештерү кәгазе

«2020 елга мәҗбүри яки төзәтү эшләре төрләрен һәм төзәтү эшләре рәвешендә административ җәза бирелә торган оешмалар исемлеген билгеләү турында»
(документның исеме һәм атамасы)

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе И.Н. Захаров

«КИЛЕШЕНДЕ»

Татарстан Республикасы буенча
Россия ҖҮФХИ ФКУнең
Нурлат муниципальара филиалы начальнигы
эчке хезмәт майоры Р.Ф. Хамидуллин